Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлегенең башкарма комитеты

# КАРАР

14 февраль 2019 ел № 2

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Надеждино авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 11 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Надеждино авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 11 мартындагы 4номерлы карарын Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән тәңгәлләштерү максатларында Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Надеждино авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 11 мартындагы 4номерлы карары атамасында һәм текстында тиешле урыннарда килешләрдәге «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Надеждино авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 11 мартындагы 4 номерлы карарының 3 бүлегендәге 5 пунктында «муниципаль заказ» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларга» алмаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.З. Галәветдинов